Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты
карары

04 март 2020 ел № 297

Әлмәт муниципаль районы территориясендә
санитар-экологик икеайлык һәм өмәләр
уздыру турында

Район территориясен санитар чистартуны тәэмин итү һәм аны халыкның экологик һәм санитар-эпидемиологик иминлеге таләпләренә җавап бирә торган халәткә китерү максатларында

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районында 2020 елның 1 апреленнән 2020 елның 31 маена кадәр санитар-экологик икеайлык, ә 2020 елның 18 апрелендә һәм 16 майда беркетелгән территорияләрне санитар чистарту һәм төзекләндерү буенча санитар-экологик өмәләр үткәрергә.

2. Түбәндәге составта санитар чистартуны һәм төзекләндерүне оештыру буенча штаб төзергә:

| | |
|---|---|
| Вәлиев Л.Ф. | - шәһәрнең штаб рәисе, башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча). |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Шабалин О.Н. | - район башкарма комитеты җитәкчесенең авыл җирлекләре белән эшләү буенча урынбасары; |
| Косарев Д.В. | - район башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары; |
| Подовалов А.Н. | - район башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары; |
| Головина В.Р. | - Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Әлмәт муниципаль районы буенча сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе (килешү буенча); |
| Маликов А.А. | - Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының Көньяк-Көнчыгыш территориаль идарәсе башлыгы (килешү буенча); |
| Исхаков А.Р. | - «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Экология һәм табигатьтән файдалану департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе директоры; |
| Павловская И.А. | - Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының мәгариф идарәсе башлыгы. |

3. Штаб рәисе Вәлиевка Л.Ф. район территорияләрен санитар чистарту һәм төзекләндерү буенча чаралар планын расларга.

4. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлегенә (Зарипова Л.Н.) халык арасында экология икеайлыгы үткәрү турында киң аңлату эшләре алып барырга.

5. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) 2020 елның 19 мартына кадәр урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы А.Н. Подовалов